**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогы авылында гражданнар җыены карары**

17.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024елда Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разезды поселогы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- зиратларны төзекләндерүгә (коймаларны яңартуга, чүп үләне белән көрәшкә), урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алуга, мәчет янындагы территориядә өскорма төзүгә, асфальт юл өслеген чокырдан ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разезды поселогында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы _________ М.К.Истиев

Гражданнар җыены секретаре _________ И.Р.Гибадуллина